**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

«30» 04 2021 ел Яр Чаллы № 1295

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Түбән Суыксу авыл җирлегенең 16:39:070401:615 кадастр номерлы җир кишәрлегенең рөхсәт ителгән файдалану төрен төп төрдән шартлы рөхсәт ителгән төргә үзгәртү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 39 статьясы, Түбән Суыксу авыл җирлеге Советының 2018 елның 20 августындагы 27-9 номерлы карары белән расланган Түбән Суыксу авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре нигезендә, Тукай муниципаль районы уставына таянып, «Якты Юл» («Светлый Путь») газетасында, Тукай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырылган 2021 елның 19 апрелендәге халык тыңлаулары бәяләмәсе нигезендә

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Түбән Суыксу авыл җирлегенең 16:39:070401:615 кадастр номерлы җир кишәрлегенең рөхсәт ителгән файдалану төрен төп төрдән (ОД-1 күпфункцияле иҗтимагый-эшлекле зона) шартлы рөхсәт ителгән төргә (шәхси торак төзелеше өчен) үзгәртергә.
2. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе А.Р. Хәбибуллин